| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

2023елның 26 октябре Иске Иштирәк № 15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Иске Иштирәк авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган «2023-2024 елларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Иске Иштирәк авыл җирлеге» җирләрен файдалану һәм саклау» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлекнең 2 абзацында «авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен» сүзләрен «җирләрнең үзлекләрен яхшырту, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу өчен» сүзләренә алмаштырырга (2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы үзидарә администрациясе бинасында Мәктәп урамы, 15 йорт; Ялтау авылында Тынычлык урамы, 27 йорт; Бәкер авылында, Нагорная урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов